# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Янгын куркынычсызлыгы турында"
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

I. "Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 (2 пунктның 7 һәм 8 өлешләре), 11 (3 пунктның 2 абзацы), 28 (1 пунктның 2 өлеше), 30 (1 пунктның 4 абзацы), 41 (1 өлеше), 43 (3 пунктның 1 абзацы), 44 (статьяның исеме) һәм 45 (1 өлеше) статьялардагы "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең" сүзләрен "Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенең" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

2) 27 (1 өлеш) һәм 28 (статьяның исеме, 1 пунктның беренче җөмләсе, 2 пунктның 1 абзацы) статьяларда "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт хезмәте" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

3) 28 (1 пунктның 1 өлеше) статьяда "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтен" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсе" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

4) 28 (2 пунктның 2 абзацы) статьясында "янгыннан сакла-

нуның һәлакәттән коткару хезмәтенең" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт идарәсенең" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

5) 30 (1 пунктның 1, 2 һәм 3 абзацлары) "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенең" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

6) 33 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Янгынга каршы күчмә техникасы булган янгыннан саклануның ведомство хезмәте бүлекчәләре янгынга каршы дәүләт хезмәтендә хисапка алыналар һәм Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсе билгеләгән тәртиптә янгын сүндерү, һәлакәттән коткаруның беренчел эшләренә җәлеп ителәләр".

7) 33 статьяның 3 өлешендә "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте" дигән сүзләрне Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсе" дип үзгәртергә.

8) 28 статьядагы (3 пункт), 33 (5 өлеш), 39 (статья исеме һәм текстта), 40 (статья исеме һәм текстта), 41 (2 өлеш), 42 (статья исеме, 1 өлеш) һәм 43 статьялардагы (статья исеме, 1 пунктның беренче җөмләсе, 1 пунктның 3 һәм 5 өлешләре) "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт хезмәте" дигән сүзләр белән алмаштырырга, 40 статьядагы "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт хезмәтенең" дигән сүзләргә алмаштырырга.

9) 43 статьяда (1 пунктның 8 өлеше) "янгыннан саклануның

һәлакәттән коткару хезмәте" дигән сүзләрне "янгынга каршы дәүләт хезмәте" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

10) 44 статьяның исемендәге "янгынга каршы дәүләт хезмәтенә" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенә" дип, тексттагы "янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәте" дип үзгәртергә.

II. Әлеге Закон басылып чыккан мизгеленнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 феврале
N 2074-XII